ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово, 422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы, 422581

06.12.2021 2 Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 500сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы?» мәсьәләсе буенча 2021 елның 6 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Рус Борнашы авылында гамәлдәге юлга вак таш салу

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 90 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 54 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирде 54 халык җыенында катнашучы; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Рус Борнашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 500сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? - Рус Борнашы авылында гамәлдәге юлга вак таш салу, дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Юматово авыл җирлегендә халык җыенының нәтиҗәләрен Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.Г.Квашнев